ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31 01 2023 г. № 69

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 8 августындагы 478 номерлы карары белән расланган урынны торак урыны, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки үзгәртеп корылырга тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 29 ноябрендәге 1535 номерлы карары нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 8 августындагы 478 номерлы карары белән расланган урынны торак урыны, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки үзгәртеп корылырга тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Алдан (проактив) режимда муниципаль хезмәтләр, гариза бирүченең әлеге муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү турында соратуны алдан бирү шартларында һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә чаралар башкарганнан соң, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләр) (http:// www.gosuslugi.ru/) техник мөмкинлекне гамәлгә ашыру аша күрсәтелә»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү гаризаны теркәгән датадан 30 көн эчендә күрсәтелә.

Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган урынны торак урыны, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки үзгәртеп корылырга тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәнең 42 пунктында каралган объектларның (торак урыннарның) җыелма исемлегенә кертелмәгән торак йортның милекчесе, хокук иясе яки наемга алучы гаризасы теркәлү көненнән 20 календарь көн эчендә карала.»;

2.5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесен таныклаучы башка документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта кирәк түгел);»;

2.10 пунктында «оешмалар тарафыннан бирелә торган» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләт бирелгән экспертлар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.0 пункты белән тулыландырырга:

«3.0. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә хезмәтләр күрсәтү тәртибен, шул исәптән уртак билгеләр белән берләшкән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата аларны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.13 пункты белән һәм әлеге бүлек белән билгеләнгән.»;

Регламентка 3 нче кушымтада:

4 пунктта «проект-эзләнү оешмасы бәяләмәсе» сүзләрен «махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов